■ Халыкара хатын-кызлар көне

2005 елның 7 мартында барыгызга да яхшы таныш, күренекле белгеч, Аллаһ юлына өндәүче Равил Үтәбай -Кәрими вафат булды. Ул, гарәп теле, көнчыгыш, ислам дине белгече буларак, рус, татар, башкорт, үзбәк, казах, төрек һәм башка телләрдә Көнчыгыш халыкларының мәгърифәтчелеге тарихын яктырткан мәкаләләр бастыра. Аның тарафыннан Р. Фәхретдин, М. Гафури, З. Кадыйри һәм башка танылган татар мәгърифәтчеләренең һәм язучыларының хезмәтләре басмага хәзерләнә. Ул ислам дине тарихы һәм кануннары буенча белешмәлекләр дә төзегән.

Равил Үтәбай-Кәрими 1933 елда Татарстан Республикасы Теләче районының Казаклар авылында дөньяга килә. 1950-1952нче елларда Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү институтында белем ала. 1956 елда Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлаганнан соң, халык мәгарифе системасында эшли. 1988-1991 елларда СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр була. 1992-1994 елларда мәдрәсә ректоры, Россия һәм БДБнең Европа өлеше илләре мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте Гыйльми советында әгъза булып тора.

Сезнең иғтибарыгызга Үтәбай-Кәриминең ислам тарихындағы беренче хатын-кыз казыя турында мәкаләсен тәкъдим итәбез.

## Галимә-казыя, мәгърифәтче Мөхлисә Буби турында

Мөхлисә Габделгалләм кызы Буби (Нигъмәтуллина) 1869 елда хәзерге Татарстан Җөмһүрияте Әгерҗе төбәгендә карарланган бәрәкәтле вә шан-шәрәфле Иж-Буби авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Бала вакытында ук дөньяви фәннәрдән, төрле телләрдән, Исламияттән төпле гыйлем-мәгълүмат алу бәхетенә ирешә. Туганнары Гобәйдулла, Габдулла мөхтәрәмнәр укыткан вә җитәкчелек кылган мәдрәсәләрдә кызлар сыйныфлары ачып, мөдирә булып, төрле фәннәрдән сабак бирә. Әйтергә кирәк, татар мәгариф тарихында эз калдырган Сара Габбасова, Мәрьям Зәйнетдинова, Рабига Идрисова һәм башкалалар Мөхлисә абыстайдан тәгълим-тәрбия күргәннәр, гыйлем эстәгәннәр.

1917 елның маенда, Мәскәү шәһәрендә, Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда мөхлисә ханымны Уфа шәһәрендә җирләшкән Мәркәз Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлыйлар. Ул олуг галимебез - мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин җитәкчелегендә хатын-кызлар арасында зур оештыру, аңлату эшләре алыр барып, җаны-тәне берлән милләткә тәрбия бирү диңгезенә чума. 1924-1927 елларда Уфада нәшер ителгән "Ислам мәҗәлләсе" сәхифәләрендә мәкаләләрен бастыра, тәгълимат-тәрбия өлкәсендә Ф. Сөләймания, Бәгъбостан ханым, Ф. Аитларның уңай тәҗрибәләрен дәвам иттерә.

1937 елның 19 ноябрь тарихында кулга алынып, нахакка гаепләнеп, 23 декабрь төнендә атып үтерелә. 1960 елның 25 маенда акланды.

Мөхлисә абыстайның исемшәрифе Русия мөселманнары арасыннан шытып калкып чыккан дөньяда иң беренче, бердәнбер һәм соңгы казыя буларак аеруча ихтирамга лаек.

Хуш, инде Мөхлисә Бубиның хезмәтен укучыларга ихлас тәкъдим кылмактамын.

**Равил ҮТӘБАЙ-КӘРИМИ,**
**Шәркыять вә Исламият галиме.**

## Мөхлисә Буби фикерләре хәзинәсеннән

1. Хәзрәти Хәдичәнең Ислам галәмендә тоткан урыны бөектер. Пәйгамбәрнең әйткәннәре - "иң бәрәкәтле хатыным": "ялганга чыгарганда ул мине раслау кылды"; "иң беренче мөэминә"; "малыдәүләте белән миңа ярдәм кылды"; "Мине тәрбияләде"; "Хәдичәдән туган балаларым - юанычларым...".

2. Исламияттә ир-атның әһәмияте һич инкарь ителми, әмма ошбу изге юлда йөзләгән хатыннар булган.

3. Хатыннарның бурычлары:

а) аз нәрсә берлә дә гаилә эчендә булганнарның күңелләрен табу;

б) тел саклау - бик яхшы вә җитеш телемез бар.

Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торырлык түгел. Эш шулай була торып - авылларда кирәгеннән артык, хәтта бөтенләй кирәкмәс вә килешми торган урыннарда урыс сүзе куллана башлаганлыгы күреләдер... Халыкларыбыз урысча белсеннәр, кулларыннан килсә, башка телләр берлә дә таныш булсыннар. Белү бик кирәк, әмма үз сүзебез арасына урынлы-урынсыз, кирәкле-кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми...

Бик тәртипле телемез бар. Бу көнне безнең бу өлкәдәге, бигрәк тә башкорт хатыннарының беренче вазифалары - үзләренең ана телләрен саклау, оныттырмау, өй эчендә - тел хуҗасы булып торудыр. Бу хезмәт алар өчен авыр түгел.

Дөньяда булган һәртөрле кавемнәрнең (милләтләрнең) телләрен саклаучылар - шул кавемнәрнең аналары вә телләре булган хәлдә - безнең халкымызның телләрен саклаучылар да - үзләренең аналары вә хатыннары булырга тиешле. Безнең халкымызның аналары, хатыннары зирәклек вә тырышлык тугърысында башкалардан ким түгел.

4. Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы - ихтыяҗга карап йөри. Дөньяда шундый урыннар вә шундый вакытлар була - башка бер урында вә башка бер заманда санга алынмый торган бер хезмәт - бик кирәкле вә бик файдалы булып чыгадыр.

**"Ислам" журналы, № 1, 1924 ел.**

## ХӘДИСЛӘР



"Иманы камил булган кешеләр күркәм холыклы булыр. Сезнең иң хөрмәтлегез - хатыннарына яхшы булганы".

"Ир белән аның хатыны бер-беренә мәрхәмәт вә мәхәббәт күзе белән караса, араларында сөешү хисе булса, барлык гөнаһлары бармак араларыннан түгелер".

"Хатыннарның иң хәерлесе һәм бәрәкәтлесе - ирләрен артык чыгымнарга салмаган хатыннар".

"Әгәр берәр хатын хуш исле майлар сөртенеп урамга чыкса һәм исе ирләрнең борынына керсен дип уйласа зиначы хөкемендә булыр, аңа караган күзләр шулай ук зина кылган хөкемендә булырлар".

"Хатыннарның ялгыз намаз укулары мәчеттә укыганга караганда егерме биш дәрәҗә яхшырак".

"Аллаһы Тәгалә бер кешегә изге хатын насыйп итсә, ул аның ярты динен сакларга ярдәм итәр. Икенче яртысын саклар өчен үзе тырышып тәкъвалык итсен".

"Бу өммәт өч нәрсәдән котыла алмады: көнчелектән, яман уйдан, начарга юраудан. Мин сезгә шул өч начар сыйфаттан котылу өчен бер юл күрсәтимме? Бер адәм турында яман уйда булсагыз, һичбер вакыт аңа начар хөкем чыгармагыз, көнләшсәгез, ул кешегә яманлык эшләмәгез, начарга юрасагыз да, тәвәккәлләп ул эшне эшләгез".

# Мөслимә хатыннар нинди булырга тиеш?

**Фатыйма ФАТКУЛЛИНА,**
**Башкортостан, Русия журналистлар берлеге әгъзасы**

**Ислам дине хатын-кызга хокуклар бирү белән беррәттән, аңа вазыйфалар да йөкли. Һәм иң зур вазыйфаларның берсе - аның ире алдында булган бурычы.**

### *Безнең бурычлар*

Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вәссәләм болай ди: "Әгәр хатын кеше көн саен биш тапкыр намазын җиренә җиткереп укыса, Рамазан аенда уразасын тотса, зина кылмаса, иренә тиешенчә буйсынса, аңа җәннәтнең үзе теләгән ишегеннән керергә рөхсәт бирелә". Ә инде икенче хәдисендә ул болай бәян итә: "Ире аннан риза булган мөслимә хатын җәннәткә керәчәк".

Динебездә хатын-кызларның ирләренә буйсынуының зарурлыгы, әлбәттә, аларны түбәнсетүдән түгел, киресенчә, гаилә бөтенлеген саклау, балалар тәрбияләүдә һәр ике якның үз бурычларын үтәвен таләп итүдән, Аллаһы Тәгаләнең мөселманнар гаиләсенә тиешле вазыйфалар билгеләп, аларның ике дөньяда да бәхетле яшәвен тәэмин итәргә кушуыннан килә.

Әгәр ир кешенең өстенә гаиләне матди яктан тәэмин итү, хатынын, балаларын ашату-эчерү, киендерү, торак урыны белән тәэмин итү йөкләнсә, гаилә иминлеген, ир-хатын арасындагы мәхәббәтне саклау, өй эчендәге тормышны ямьле, күңелле итү - хатын-кызның изге бурычы. Хезмәтем буенча күп хатын-кызлар миңа үзләренең проблемалары, кайгы-хәсрәтләре белән мөрәҗәгать итә. Яшь хатын-кызлар гына түгел, өлкән буын апаларның да ирләре каршындагы бурычларын аңламавын күрү күңелдә аянычлы тойгылар уята.

Үсеп җиткән уллары кинәт үлеп киткәч, бер ханым мәчеткә укырга йөри башлый, намазга баса. Әмма ире белән мөнәсәбәтләре көннән-көн начарая. Үзенең хәлләрен сөйли торгач, ул инде бер елдан артык икесе ике караватта йоклауларын әйтте. Шунда мин аңа Пәйгамбәребезнең бер хәдисен китердем: "Әгәр ире хатынын бергә йокларга чакырган чакта хатыны аның янына ятмаса, ире аңа ачуланып төнен үткәрсә, фәрештәләр бу хатынны иртәнгә кадәр ләгънәт кылачак".

Аллаһының Рәсүле (с.г.в.) үзенең бу хәдисендә хатыннар өстендә булган иң зур бурычны аңлата. Кызганыч ки, безнең татар, башкорт хатыннары, шушы бурычны аңламаганлыктан, күпме хаталар, гөнаһ кыла. Уйлап карасаң, фәрештәләр ләгънәт кылган хатын Аллаһы Тәгаләнең дә ләгънәтенә тарыячак бит.

Мөслимә хатын эштән кайткан ирен матур итеп бизәнеп, тәмле ашлар пешереп, балаларын да тиешенчә тәрбияләп каршы алырга тиеш. Көн озынына эштә арып-талчыгып кайткан мөселман ир, үзен шатланып көтеп алган хатынын һәм балаларын күрү белән, арыганнарын оныта. Тәмле ризык ашап, бераз ял иткәннән соң, аңа да балалары белән аралашу, аларга тиешле тәрбия бирү, ата буларак ярдәм күрсәтү күңелле эшкә әверелә.

### *Гаиләдәге татулык хакында*

Кызганыч ки, безнең чынбарлыкта хатын-кызларыбыз өйләрендә иске халат, карар күзгә ямьсез, иске киемнәр киеп, чәчне-башны туздырып йөрергә гадәтләнгән. Ә инде эшкә китә башласа яисә урамга чыгарга җыенса, хатын-кызларыбыз матур итеп киенергә, бизәнергә тотына. Димәк, аның бу бизәнүе башка ирләр, кешеләр күрсен өчен килеп чыга. Ә бит чынлыкта хатын кеше ире янында гүзәл, ягымлы, тәмле телле булырга тиеш. Чит ирләр янында чытлыкланып, зиннәтләрне - чәчләрне, аякларны, муен-күкрәкләрне күрсәтеп йөрү Коръәндә тыелган, бу зина дип атала. Мондый хәрам эшләрне эшләгән өчен хатын-кызлар җәһәннәмдә газап кылыначак.

Гаиләдәге татулыкны, бердәмлекне, өлфәт мәхәббәтне саклау өчен мөслимә хатыннар бөтен көчләрен салалар. Еш кына тормышта шундый хәлләрне күзәтергә туры килә. Әйтик, ир кеше нәрсәгә булса да ачуланып, хатынына бер авыр сүз әйтә. Хатын кеше аңа тагын да катырак җавап бирә, менә шуннан ызгыш китә. Йә булмаса, хатын кеше үпкәләп, иренә көннәр буена дәшмичә йөри. Әйткән авыр сүзне айлар буена хәтерендә тота, оныта алмый газаплана.

Мөслимә хатыннарга бу җәһәттән киңәш өчен бер галимнең сүзләрен китерәсе килә: "Ир кеше ачуланганда сүзләрен тел белән әйтә дә, тиз генә оныта да. Ә хатын кеше сүзләрен йөрәк аша үткәреп әйтә һәм шулай ук кабул итә. Хәтта айлар буена үпкәләп тә йөри. Шуңа күрә хатын кешегә иренең ачуланган вакытта әйткән сүзләрен җиңел кабул итәргә, онытырга, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү өчен гаиләдәге татулык хакына, ире гаепле булган очракта да, аннан гафу үтенеп, үзе аның янына башлап килергә тиеш". Бу җәһәттән Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шундый хәдисе бар: "Шундый хатыннар сезнең арагыздан җәннәткә керәчәк, әгәр ире аны рәнҗетсә яисә үзе ирен үпкәләтсә, беренче булып иренә якын килеп, кулын аның кулларына куеп, "Син миннән риза булмыйча торып, мин күзләремне йомып йокыга китә алмаячакмын!" - дияр".